РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Уразаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Н.Бадертдинова , д. 35, село Уразаево,
Азнакаевского муниципального района РТ
423303

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Уразай авылы җирлеге
башлыгы

Н.Бадертдинов урамы, 35,Уразай авылы
Азнакай муниципаль районы ТР
423303

Тел./факс(885592)43-5-55; E-mail:Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
24 октябрь 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында, Уразай авылында Речная урамы 1 нче йорттан 23А нче йортка, Садовая урамы 2 нче йорттан 4 нче йортка, Энгельс урамы 1 нче йорттан 131 нче йортка кадэр теркэлгэн һэм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елның 03 ноябрендэ 15 сэгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында, Уразай авылында Н.Бадертдинов 1 нче йорттан 36А нчы йортка, Гараж урамы 1 нче йорттан 4 нче йортка, Яшьлэр урамы 1/1 нче йорттан 70 нчы йортка, Подгорная урамы 1 нче йорттан 32 нчы йортка кадэр теркэлгэн һэм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елның 03 ноябрендэ 16 сэгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында үзара салым кертү мэсьэлэсе буенча халык җыенын

оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты.;

- - гражданнар жыенының беренче этабын уздыру вакыты-2023 елның 03 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар жыенының икенче этабын уздыру вакыты-2022 елның 08 ноябрендә 16.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

-гражданнар жыенын уздыру урыны-Уразай авылы, Энгельс урамы, 63 нче йорт, Уразай авыл Мэдэният йорты залы;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 24 октяберennнән дә соңга калмыйча гражданнарга Уразай авылы, Н.Бадертдинов урамы, 35 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитетында мэгълумат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә.;

-Уразай торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшэучелэр исемлеген тозергэ;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Уразай торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарнын җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләр һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнар тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлту белән килешәсезме:

- Уразай авылының тышкы урам яктырту челтәрләрен ремонтлау;

-Уразай авылында 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар хөрмәтенә һәйкәл төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

-Уразай авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту .

Уразай авылының тышкы урам яктырту челтәрләрен ремонтлау( урам яктырту өчен электр товарлары сатып алу, урам яктырту яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү) ;

Уразай авылында 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар хөрмәтенә һәйкәл төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- Уразай авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(тракторчыга механизацияләнгән кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Уразай авылы, Н.Бадертдинов ур., 35 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башлык: А.М.Шарифуллина